**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 18 апрель № 236

г. Казань

Инвалидларның аерым категорияләренә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбенннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү турында

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законының $8^2$ статьясын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбенннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) күләмен билгеләү тәртибен;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбенннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү тәртибен.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгын Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешнең 4 нче пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән авырган инвалидларга, шулай ук әлеге исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән авырган инвалид балалары булган, билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗ дип танылган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә куелган гаиләләргә (алга таба – субсидия алучылар) торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү буенча чаралар үткәрүгә вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

Татарстан Республикасы бюджеты счетларына хезмәтләр күрсәтүгә вәкаләтле банк белән субсидия алучыларның аерым ябык максатчан шәхси счетларына хезмәтләр күрсәтүгә шартнамә төзергә;

тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы

Татарстан Республикасы законында әлеге максатларга күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирүне тәэмин итәргә;

квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 15 еннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына субсидия алучыларны торак белән тәэмин итүгә бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчасыннан файдалану турында хисап кертергә.

4. Бу карарның гамәле 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\236.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 18 апрель, 236 нчы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбенннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) күләмен билгеләү тәртибе**

1. Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешнең 4 нче пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән авырган инвалидларга, шулай ук әлеге исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән авырган инвалид балалары булган, билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗ дип танылган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә куелган гаиләләргә (алга таба – субсидия алучылар) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

С = СРС х 18 кв. метр, монда:

С – торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) күләме;

СРС – Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтләр бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларына субсидияләр бирелгән гражданнар реестрларын җибәргән көндә гамәлдә булган Татарстан Республикасы буенча торакның гомуми мәйданының бер квадрат метрына уртача базар кыйммәте.

2. Субсидия алучыларның «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 ел, 24 ноябрь, ФЗ-181 нче Федераль законның 17 статьясындагы алтынчы өлештә каралган өстәмә торак мәйданга хокукы булганда, торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

С = СРС х (18 кв. метр + 15 кв. метр), монда:

С – торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) күләме,

СРС – Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтләр бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларына субсидияләр бирелгән гражданнар реестрларын җибәргән көндә гамәлдә булган Татарстан Республикасы буенча торакның гомуми мәйданының бер квадрат метрына уртача базар кыйммәте.

---

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 18 апрель, 236 нчы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбенннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү тәртибе**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешнең 4 нче пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән авырган инвалидларга, шулай ук әлеге исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән авырган инвалид балалары булган, билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗ дип танылган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә куелган гаиләләргә (алга таба – субсидия алучылар) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) (алга таба – торак сатып алуга субсидия) бирү механизмын билгели.

II. Торак сатып алуга субсидия бирү тәртибе

2. Әлеге Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән гражданнарга торак сатып алуга субсидияләр бирү бу Нигезләмәнең 1 нче пунктында күрсәтелгән вакыт эчендә субсидия алучылар билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗ дип танылган (алга таба – торак урыннар бирүгә мохтаҗлар) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларының исемлекләре нигезендә Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан төзелгән субсидия алучы гражданнарның җыелма исемлеге (алга таба – җыелма исемлек) буенча чират тәртибендә башкарыла. Әлеге исемлекләр субсидия алучы бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗ буларак исәпкә куелган көннән соң биш эш көне эчендә вәкаләтле органга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары тарафыннан кертелә.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары субсидия алучыларның торак сатып алу өчен субсидия бирүгә хокукын үзгәртүгә китергән хәлләр килеп чыгуы турында мондый хәлләр килеп чыккан көннән соң ун көн эчендә вәкаләтле органга хәбәр итәләр.

Җыелма исемлекләр субсидия алучылар торак урыннар бирүгә мохтаҗлар буларак исәпкә куелган хронологик эзлеклелекне исәпкә алып төзелә.

Бер үк көндә исәпкә куелган субсидия алучылар җыелма исемлектә алфавит тәртибендә күрсәтелә.

3. Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында билгеләнгән субсидия алучыларның чират тәртибендә вәкаләтле органга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары хакында мәгълүмат кергән көннән соң җиде эш көне эчендә, тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре күләменнән чыгып, әлеге Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча торак сатып алуга субсидияләр бирелә торган субсидия алучылар реестрларын (алга таба – реестрлар) төзи һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларына җибәрә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары:

торак шартларын яхшыртуда мохтаҗлыкны саклау өлешендә һәм, вәкаләтле органның территориаль социаль яклау органнары белән берлектә, реестрга кертелгән субсидияләр алучыларның ташлама категориясенә каравы өлешендә реестрларны актуальләштерүне гамәлгә ашыра;

субсидия алучы торак шартларын яхшыртуда мохтаҗлыгын раслаган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә субсидия алучыга әлеге Тәртипкә теркәлгән 3 нче кушымтада китерелгән форма буенча торак сатып алуга субсидия бирү турындагы хәбәрнамә белән Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бирү хакында хәбәр итә;

вәкаләтле органнан реестрны алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 35 көн эчендә һәр субсидия алучының торак шартларын яхшыртуга үз хокукын тормышка ашыру мөмкинлеге турында вәкаләтле органга хәбәр итә.

5. Торак сатып алуга субсидия бирү турындагы хәбәрнамәне алганнан соң, субсидия алучылар яки аларның законлы вәкилләре ябык максатчан шәхси счетны ачтырыр өчен хәбәрнамәдә күрсәтелгән адрес буенча мөрәҗәгать итәләр.

6. Торак сатып алу максатларында, субсидия алучыга яисә аның законлы вәкиленә, гражданның булачак үз фатирында катнашу, сайлау һәм бирү беркетмәсен теркәп, субсидия алучы яки аның законлы вәкиле исеменнән махсуслаштырылган оешма белән төзелгән шартнамәне, яисә торак урын сату-алу шартнамәсен, яисә күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм алар белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыра торган органда теркәлгән, субсидия алучыны кимендә 18 кв.метр гомуми мәйданлы торак белән тәэмин итә торган башка шартнамәне, милек хокукын теркәү хакындагы шаһәдатнамәне теркәп, территориаль социаль яклау органына кертергә кирәк. Кертелгән шартнамәдә сатып алына торган торак мәйданы өчен түләү әлеге карар нигезендә бирелгән торак урын сатып алуга субсидияне исәпкә алып башкарылачак дигән пункт булырга тиеш.

7. Шартнамә буенча торак урын кыйммәте торак сатып алуга субсидия күләменнән арткан очракта җитми торган сумма субсидия алучының үз акчасы исәбеннән түләнергә тиеш.

8. Территориаль социаль яклау органы атна саен вәкаләтле органга субсидия алучылар яки аларның законлы вәкилләре тарафыннан әлеге Тәртипнең 6 нчы пункты нигезендә бу Тәртипкә теркәлгән 4 нче кушымтада күрсәтелгән формага ярашлы рәвештә кертелгән шартнамәләр турында мәгълүмат җибәрә.

9. Территориаль социаль яклау органыннан субсидия алучылар яисә аларның законлы вәкилләре тарафыннан кертелгән шартнамәләр турында мәгълүмат алганнан соң биш эш көне эчендә вәкаләтле орган тиешле акчаның Татарстан Республикасы бюджеты счетларына хезмәтләр күрсәтүгә вәкаләтле банк (алга таба – вәкаләтле банк) счетына күчерелүен тәэмин итә һәм вәкаләтле банкка «ТХТ» форматында субсидияләр алучылар реестрларын җибәрә. Реестрда түләү йөкләмәсенең саны һәм датасы күрсәтелергә һәм субсидия алучының түбәндәге мәгълүматлары кертелергә тиеш: фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, паспорт мәгълүматлары, теркәлгән адресы, субсидия алучыга торак алыр өчен бирелергә тиешле субсидия суммасы, аерым ябык максатчан шәхси счет номеры.

10. Вәкаләтле банк бүлеге:

банкның корреспондент счетына акчалар күчерелгән һәм субсидияләр алучылар реестры кертелгән көннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча акчаны субсидияләр алучыларның аерым ябык максатчан шәхси счетларына күчерә һәм бу турыда вәкаләтле органга хәбәр итә;

акчаны (торак сатып алуга субсидияне) субсидия алучының счетына күчергәннән соң, субсидия алучының язма гаризасы нигезендә, гаризаны алган көннән өч эш көне эчендә акчаны торак урынны сатучыга яисә торак урын таләп итү хокукы булган затка күчерә;

акчаны торак урынны сатучыга яисә торак урын таләп итү хокукы булган затка күчергән көннән соң өч эш көне эчендә вәкаләтле органга субсидия алучының торак сатып алуга субсидиядән файдалануы турында хәбәр итә.

11. Вәкаләтле орган вәкаләтле банк бүлегеннән мәгълүмат алганнан соң өч эш көне эчендә субсидия алучыга аның аерым ябык максатчан шәхси счетына акча күчерелүе хакында хәбәр итә.

Субсидия алучы вәкаләтле органнан үзенең аерым ябык максатчан шәхси счетына акча күчүе турында мәгълүмат алганнан соң, вәкаләтле банк бүлегенә акчаны торак урынны сатучыга яисә торак урын таләп итү хокукы булган затка күчерү хакында гариза тапшыра.

12. Субсидия алучы торак сатып алуга субсидия бирү турында хәбәрнамә алган көннән өч ай эчендә торак шартларын яхшырту хокукын тормышка ашырмаса, әлеге вакыт чыкканнан соң биш эш көне эчендә вәкаләтле орган аны әлеге Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән реестрдан сыза һәм аңа тиешле хәбәрнамә җибәрә.

Бу очракта субсидия алучы үзенең торак сатып алу өчен субсидиягә хокукын югалтмый, субсидия алучы гражданнарның җыелма исемлегендә кала һәм алга таба гариза нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан әлеге Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән чираттагы төзелә торган реестрга кертелергә тиеш.

Әлеге пунктта билгеләнгән өч айлык вакыт, субсидия алучы торак сатып алуга субсидияне тормышка ашыру вакытын озайту хакында язма рәвештә гариза

тапшырган очракта, агымдагы ел дәвамында вәкаләтле орган тарафыннан бер тапкыр бер айга озайтыла.

13. Вәкаләтле орган вәкаләтле банк бүлегеннән акчаны торак урынны сатучыга яисә торак урын таләп итү хокукы булган затка күчерү турында хәбәрнамә алган көннән соң өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларына субсидия алучының торак сатып алуга субсидиядән файдалануы хакында хәбәр итә.

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбенннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

___________________________________________________________ буенча
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге исеме)

20___ елның ________ хәленә карата
Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешнең 4 нче пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән авырган инвалидлар, шулай ук әлеге исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән авырган инвалид балалары булган, билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗ дип танылган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә куелган гаиләләр исемлеге

| Фамилиясе | Исеме | Анасының исеме | Торак белән тәэмин итүгә хокук бирә торган категория (1 – инвалид, 2 – инвалид бала булган гаилә) | Ташламаларга хокук бирә торган документ реквизитлары | | | | | СНИЛС | Шәхесне таныклый торган документ реквизитлары | | | | | Җенесе | Туган көне | Теркәлгән адресы (текст форматы) | | Исәпкә кую датасы | Өстәмә торак мәйданына хокукы (0 – хокукы юк, 1 – хокукы бар) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | документның исеме | сериясе | саны | бирелгән датасы | кем тарафыннан бирелгән | | документның исеме | сериясе | саны | бирелгән датасы | кем тарафыннан бирелгән | | | муниципаль берәмлек исеме | шәһәр (авыл җирлеге), урам, йорт саны, фатир саны | | |

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбенннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү тәртибенә
2 нче кушымта

Форма

________________________________________________________ буенча
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге исеме)

20___ елның ________ хәленә карата
торак урын сатып алуга торак субсидияләр (бер тапкыр акчалата түләүләр) бирелә торган
Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешнең 4 нче пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән авырган инвалидлар, шулай ук әлеге исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән авырган инвалид балалары булган, билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗ дип танылган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә куелган гаиләләр
реестры

| Фамилиясе | Исеме | Әтисенең исеме | Торак белән тәэмин итүгә хокук бирә торган категория (1 – инвалид, 2 –- инвалид бала булган гаилә) | Җе-несе | Туган көне | Теркәлгән адресы | | Исәпкә кую датасы | Өстәмә торак мәйданына хокукы (0 – хокукы юк, 1 – хокукы бар) | Субсидия күләме |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | муниципаль берәмлек исеме | шәһәр (авыл җирлеге), урам, йорт саны, фатир саны | | | |

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннңнән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү тәртибенә
3 нче кушымта

Форма

______________________________________________________________________

Субсидия алучының Ф.И.Ат.и.

______________________________________________________________________

яшәү урыны адресы

______________________________________________________________________

паспорт мәгълүматлары

## Торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү турында хәбәрнамә

Сез, торак урыннар бирүгә мохтаҗ буларак, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннңнән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) алырга хокуклы.

Алга таба әлеге субсидия күчereләчәк аерым ябык максатчан шәхси счет ачтырыр өчен, Сезгә Татарстан Республикасы бюджеты счетларына хезмәтләр күрсәтүгә вәкаләтле банк (алга таба – вәкаләтле банк) бүлегенә түбәндәге адрес буенча мөрәҗәгать итәргә кирәк:

______________________________________________________________________________.

(банкның исеме һәм адресы күрсәтелә)

Торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) сыйфатында бирелә торган акча исәбеннән торак сатып алу максатларында, Сез торак урынны сату-алу шартнамәсен яисә күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм алар белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыра торган органда теркәлгән башка шартнамәне территориаль социаль яклау органына кертергә тиеш, шуннан соң Сез вәкаләтле банк бүлегендә ачтырган счетка торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) күләмендә финанс чаралары күчереләчәк, алга таба Сез вәкаләтле банк бүлегенә тапшырган гариза нигезендә алар турыдан-туры Сез сатып ала торган торак урынны сатучыга яки Сез сатып ала торган торак урын таләп итү хокукы булган затка күчереләчәк.

Кертелгән шартнамәгә сатып алына торган торак мәйданы өчен түләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 18 апрель, 236 нчы карары нигезендә бирелгән торак урын сатып алуга торак субсидиясен (бер тапкыр акчалата түләүне) исәпкә алып башкарылачак дигән пункт өстәргә кирәк булуына игътибарыгызны юнәлтәбез.

Торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) алудан баш тарткан яисә әлеге хәбәрнамәне алган көннән соң өч ай эчендә торак шартларын яхшырту хокукын тормышка ашырмаган очракта, Сез торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирелгән гражданнар реестрыннан сызылачаксыз. Шул ук вакытта Сез әлеге субсидиягә хокукыгызны югалтмаячаксыз һәм торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) алучыларның җыелма исемлегендә калачаксыз. Алга таба Сезнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына җибәрелгән шәхси

гариза буенча Сез яңадан торак урын сатып алуга торак субсидияләре (бер тапкыр акчалата түләүләр) бирелә торган гражданнар реестрына кертеләчәксез.

Әлеге Хәбәрнамәнең бишенче абзацында күрсәтелгән вакыт, Сез Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына язма рәвештә гариза тапшырган очракта, агымдагы ел дәвамында бер тапкыр бер айга озайтылачак.

Торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) күләме ____________ сум тәшкил итә.

Торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) алырга риза, торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү шартлары белән таныштым һәм аларны үтәү йөкләмәсен үз өстемә алам.

____________________________________________________________________________

(Хәбәрнамә җибәрелгән затның Ф.И.Ат.и., имзасы, дата)

Торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) алудан баш тартам.

____________________________________________________________________________

(сәбәбен күрсәтергә)

Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты җитәкчесе

_____________ ____________________

имзасы имзаның аңлатмасы

м.у.

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбенннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү тәртибенә 4 нче кушымта

Форма

Субсидия алучылар тарафыннан кертелгән
милеккә торак сатып алуга шартнамәләр турында мәгълүмат

| Т/с | Ф.И.Ат.и. | Адресы | Паспорт мәгълүматлары | счет № | Шартнамә төре |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

_______________________________________________________________________________

(Исемлек төзегән затның Ф.И.Ат.и., вазыйфасы, имзасы)

м.у.

F:\KARAR\2016\236.docx